СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2014 Әгерҗе шәһәре № 32-4

Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Расларга:

Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында нигезләмә (1 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районы agryz.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Ә. Закировага йөкләргә.

Совет Рәисе
Муниципаль районы Башлыгы В.В.МАКАРОВ

Общий отдел
Гомуми бүлек

Әгерҗе муниципаль районы
Советының 09.04.2014 ел, № 32-4
карарына 1 нче кушымта

# Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә белән Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек Вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия даими эшләүче орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервын формалаштыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр нигезендә төзелгән башка муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссиянең персональ һәм сан составы Әгерҗе муниципаль районы Советы тарафыннан төзелә һәмраслана.

## II. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

4. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

1) Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыруны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

2) Әгерҗе муниципаль районы составына керүче Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, җирлекләрнең кадрлар резервын булдыру эшчәнлеген координацияләү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге вазыйфаларны башкара:

1) Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турындагы Нигезләмә нигезендә кадрлар резервына кертү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү (алга таба - кадрлар резервы турындагы нигезләмә);

2) һәр дәгъвачының баллы бәяләү системасына нигезләнгән дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алу методикасын раслау;

3) Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, Әгерҗе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең вакантлы вазыйфалар биләү өчен дәгъва кылуда ихтыяҗына ел саен бәя бирү.

## III. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

6. Комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен хокуклы:

1) Әгерҗе муниципаль районы составына керүче җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан Комиссия эшчәнлеген башкару өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга һәм алырга;

2) үз утырышларына чакырырга һәм гражданин дәгъва кылган вазыйфа буенча эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча экспертлар фикерен тыңларга;

3) гражданнарга тест үткәрү һәм аларның һәркайсына аның психологик портретын төзү өчен дәүләт мәгариф учреждениеләре белән килешүләр төзергә.

7. Комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен бурычлы:

1) Әгерҗе муниципаль районы составына керүче гражданнарга һәм җирле үзидарә органнарына кадрлар резервына кертүгә, конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләренә конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү һәм гражданнарны кадрлар резервыннан төшереп калдыру турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

2) дәгъвачыларның кадрлар резервына башлангыч исемлеген формалаштыру максатларында Әгерҗе муниципаль районы, Әгерҗе муниципаль районы составына керә торган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан тәкъдим ителгән документларны һәм материалларны карарга һәм эксперт бәяләмәсен үткәрергә;

3) үзе тәкъдим иткән анкетада күрсәтелгән шәхси мәгълүматлардан файдалануга дәгъва кылучыдан язма ризалык алырга;

4) конкурс сайлап алуның беренче этабын уздыру йомгаклары буенча кадрлар резервы турында нигезләмәдә каралган карарларның берсен кабул итәргә һәм аның турында язма рәвештә дәгъвачыларны конкурс сайлауның икенче этабын үткәрүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һәм җирле үзидарәнең тиешле органнары тарафыннан язма рәвештә хәбәр итәргә;

5) конкурста сайлап алуның икенче этабында һәр дәгъвачының йомгаклау баллын билгеләү белән дәгъвачылар бәяләвен үткәрергә;

6) конкурс сайлавының икенче этабында катнашучы дәгъвачыларны кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә;

7) кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләү буенча гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашырырга;

8) Әгерҗе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан ел саен тапшырыла торган гомумиләштерергә һәм анализларга, кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләүнең индивидуаль планнарын үтәү турында хисап ясарга;

9) кадрлар резервы турында нигезләмәдә каралган очракларда гражданны кадрлар резервыннан төшереп калдыру турында карар кабул итәргә;

10) Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервына кертелгән гражданнар исемлеге урнаштыруны тәэмин итәргә.

## IV. Комиссиянең эш тәртибе

8. Комиссия утырышлары вакантлы вазыйфаларны биләү өчен дәгъва кылуда Әгерҗе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары ихтыяҗы ихтималын ел саен бәяләү нәтиҗәсендә төзелә торган Комиссиянең эш планы нигезендә үткәрелә. Кирәк була калса, комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырыла ала.

9. Комиссия комиссия рәисе, секретаре һәм комиссия әгъзаларыннан (алга таба - комиссия әгъзалары) тора.

10. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) Комиссиянең эш планын раслый, Комиссиянең чираттан тыш утырышын чакыру турында карар кабул итә;

3) Комиссия утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

4) Комиссия утырышларында рәислек итә;

5) утырышлар, хатлар һәм Комиссия карары беркетмәләренә имза сала;

6) үз компетенциясе чикләрендә Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп тора.

11. Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Комиссия эше планнарын әзерләүне тәэмин итә;

2) Комиссия әгъзаларына Комиссиянең утырышын уздыру урыны һәм вакыты турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

3) Комиссиягә керә торган документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны Комиссия утырышына карау өчен әзерли;

4) Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) балларны кон-курста сайлап алуның икенче этабында җыелган дәгъвачылар тарафыннан санауны гамәлгә ашыра;

5) Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен, хатларны һәм Комис-сиянең карарларын рәсмиләштерә.

12. Комиссиянең башка әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Комиссия утырышларында, карарлар проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

4) тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары белән танышалар.

13.Комиссия әгъзалары саны 7 кеше тәшкил итә.

14. Комиссия утырышы, әгәр анда аның барлык әгъзалары да булса, хокуклы дип санала.

15. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән Комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

16. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм конкурс сайлавын дәгъвачыларның һәркайсының йомгаклау баллары утырыш беркетмәсендә теркәлә һәм Комиссия карары белән рәсмиләштерелә.

17. Комиссия утырышы карары һәм беркетмәсенә аның рәисе имза сала.

18. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү, утырышлар беркетмәләрен һәм Комиссия карарларын саклау буенча оештыру-техник эшне башкару бурычлары Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә йөкләнә.

19. Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

Әгерҗе муниципаль районы
Советының 09.04.2014 ел, № 32-4
карарына 2 нче кушымта

Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Закирова Резида Әмировна – Әгерҗе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| Комиссия секретаре | Хәкимова Надежда Минзаһитовна - Башкарма комитетның юридик бүлеге баш белгече |
| Комиссия әгъзалары | 1.Панков Александр Леонидович - Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы<br>2.Чураева Айгөл Ринатовна - коррупциягә каршы көрәш буенча район Башлыгы ярдәмчесе<br>3. Зарипова Рәмзия Сабировна - "ТАТМЕДИА" ААҖ филиалы баш мөхәррире (килештерү буенча)<br>4. Иванов Руслан Валерьевич – Башкарма комитет җитәкчесенең мөлкәт һәм икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары<br>5. Фархетдинова Ризеда Салиховна- Әгерҗе шәһәренең 3 нче урта мәктәбе директоры, “Бөтендөнья татар конгрессы” Әгерҗе җирле бүлекчәсе секретаре (килештерү буенча) |